СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД ИННОПОЛИС»
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район, Республика
Татарстан, 420500

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ
«ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ»
СОВЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

РЕШЕНИЕ КАРАР

___ 06.10.2022 ____ 12-71
№________________

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Мэрын һәм муниципаль хезмәткәрләрен хезмәт өчен түләү, гарантияләр, премия бирү, матди ярдәм түләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 29 апрелендәге 8-50 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясе хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 7 пунктына таянып

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы
карар итте:

1. «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Мэрын һәм муниципаль хезмәткәрләрен хезмәт өчен түләү, гарантияләр, премия бирү, матди ярдәм түләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 29 апрелендәге 8-50 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Мэрын һәм муниципаль хезмәткәрләрен хезмәт өчен түләү, гарантияләр, премия бирү, матди ярдәм түләү, бүләкләү турындагы Нигезләмәнең 3 бүлегенең 3.9.1 пунктындагы 3 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.1. 28 календарь көннән артык отпускның бер өлеше, муниципаль хезмәткәрнең язма гаризасы буенча, Россия Федерациясе Хезмәт кодексында башкасы каралмаган булса, отпуск бирелә торган эш елы тәмамланганнан соң акчалата компенсация белән алмаштырылырга мөмкин».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми

порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районы мәгълүмати сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Интернет челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/), шулай ук Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Иннополис шәһәре Мэры                                        Р. Р. Шагалиев